

Галимҗан Гыйльманов

# САМАТ БАТЫР



Галимҗан
Гыйльманов

# САМАТ БАТЫР

Балалар өчен шигырьләр, җырлар,
табышмаклар, әкиятләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г92

Гыйльманов, Г. Х.

Г92 Самат батыр : балалар өчен шигырьләр, җырлар, табышмаклар, әкиятләр / Галимҗан Гыйльманов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 439 б.

ISBN 978-5-298-02191-3

Китапта авторның балалар өчен язылган шигырьләре, җырлары, табышмаклары һәм әкиятләре тупланды. Маҗаралы вакыйгаларны үз эченә алган һәм балаларга аңлаешлы, җиңел тел белән язылган шигырьләр аша укучы тирә-юньне танып белергә өйрәнә. Кызыклы табышмаклар балаларның уйлау, фикерләү сәләтен үстерә.

Китап мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларга, ата-аналарга, укытучыларга, тәрбиячеләргә, татар балалар әдәбияты белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02191-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Гыйльманов Г. Х., 2012



# МИН БЕЛГӘН МАЛАЙ

## МИН — ЧЫН ТАТАР МАЛАЕ!

Әйдәгез танышыйк:
Галимҗан – исемем.
Рас килә, ди әти,
Исемгә җисемем.
Чатнатып сөйләшәм
Үз ана телемдә.
Оялмыйм, курыкмыйм,
Мин бит үз илемдә!
Үземне Ватанны
Сакларга әзерлим;
Дөресен әйткәндә,
Күптәннән әзер мин!
Башымда чигүле,
Каюлы түбәтәй.
Догалар укырга
Өйрәтә дәү әти.
Әйткәнне көтмичә,
Әнигә булышам.
Яшермим, аз гына
Абыйдан калышам...

Тәүфыйклы булырга
Кирәген беләм мин.
Чын татар малае
Йөрәгем белән мин!

# АРИФМЕТИКА

Кечкенәдән, өч яшемнән,
Хисап фәнен яраттым.
Төгәл санап бирә идем
Ике атын пар атның.

Дүрт яшь тулганда, әнкәйнең
Биш шикәрен урладым.
Алуын алтыны алдым,
Берсен санап тормадым.

Көн дә кичен саный идем:
«Унөч егылдым, – диеп. –
Дүрт мәртәбә су коендым,
Дүрт батмый калдым», – диеп.

Җәй буена алты тапкыр
Туп тигән тәрәзәгә.
Бер елны биш тапкыр барды
Әнием күрәзәгә.

Сораган: «Тынгысыз бигрәк,
Кем булып үсәр икән?
Әле генә күлмәк алдым,
Күпмегә түзәр икән?»

Ун көнгә түзде ул күлмәк,
Мин яхшы саный беләм!
Күлгә барып, балык сөздек
Дүрт тапкыр абый белән.

Җиде яшьтә алфавитның
Бар хәрефен өйрәндем.
Унбиш яшьтә батыр калдым,
Егермедә өйләндем.

Көтүдәге бәрәннәрне
Әле дә саныйм төштә...
Югыйсә мин үстем инде –
Биш тапкыр сигез яшьтә!

# МИН БЕЛГӘН МАЛАЙ

Мин белә-белгәннән бирле,
Бер малай яши бездә.
«Ничә яшьтә ул?» – дисезме,
Зур инде ул – сигездә!

Әллә ни усал да түгел,
Юаш та түгел алай.
Бик шәп тә, начар да түгел, –
Уртача гына малай.

Мактанчык түгел, болай да
Әйбәтлеген beләләр.
Урамга чыкса, малайлар
Шундук чабып киләләр.

Малайлар үз итә аны,
Кызлар да хөрмәт итә.
Һәрбер көнне күрше Алсу
Капка төбендә көтә.

Мәктәпкә бергә баралар
Һәм бергә утыралар.
Яннарында кызлар булса,
Малайлар батыр алар!

Бу малай да батырая,
Янында Алсу булса.
Төннәрен дә курыкмый ул,
Янында кемдер кунса.

Иртән торгач, аның белән
Очрашамын көн дә мин.
Әйтсәм, шундук беләчәксез,
Шуңа күрә «мин» димим...

## «ПӨХТӘ МАЛАЙ»

Мин бүген бик «пөхтә малай»,
Мин бүген шундый чиста,
Мин бүген шундый акыллы,
Мин бүген шундый оста!

Күпме генә уйнасам да
Тапланмады күлмәгем.
Егылсам да, бишмәтемнең
Өзмәдем бер элмәген.

Төймәләрем урынында,
Чалбарым ертылмады.
Кермәгән тишек калмады,
Төшмәгән яр калмады.

Елгада балык сөздем мин,
Ни генә кыланмадым.
Пычрандым инде дигәндә,
Пычранмый калам тагын.

Юешләнмәдем, күлендә
Йөзеп йөрсәм дә чыкның...
Чөнки мин бүген абыйның
Киемен киеп чыктым.

## УЙЛАП АРДЫМ

Бүген иртән уяндым да
Озак уйланып яттым.
Уйлана торгач, бик матур,
Әйбәт уй уйлап таптым.

Нәрсә булыр икән, димен,
Әнигә ярдәм итсәм?
Җанга тигән ялкаулыкны
Бераз гына киметсәм?
Түшәгемне җыеп куйсам,
Иртән иртүк торуга.
Әйтмәс борын чыгып чапсам
Әбиемә даруга?
Казыбызның бәбкәләрен
Тилгәннән саклап йөрсәм?
Басудагы әтиемә
Аш илтергә өлгерсәм?
Кече энемне карасам,
Әнием эштә чакта?
Көлеп кенә торыр иде,
Йөртсәм аны кочакта.
Су сибеп чыксам гөлләргә,
Әнием әйтмәсә дә?
Утын кертсәм, су ташысам,
Тагын мең эш эшләсәм,
Бу эшләрне эшләгәндә,
Чалбарымны тишмәсәм...

Әйбәт булыр иде дә бит,
Бер бәлагә тардым мин:
«Ничек әйбәт булыйм?» – диеп
Уйлый-уйлый ардым мин!

# ИХ, ҮСӘРГӘ!

Иртәнге кояш белән үк
Тышка чыгып йөгерәм.
Бар малайдан алда торып,
Мин үсәргә өлгерәм.

Күрше Азат бәп-бәләкәй,
Ул йокларга ярата.
Белмиләр – мин үсеп алам,
Ул йоклаган арада.

Кояш нуры яктысында
Мин шулай көн дә үсәм.
Арттыру булмас, кояш ул
Бик тә тылсымлы, дисәм.

Йөгергән чакта да үсәм,
Сикергәндә дә үсәм.
Егылганда да үсәм мин,
Шуңа еламыйм, түзәм.

Кычыткан чакса да үсәм,
Урманда йөргәндә дә.
Әрәмәлек уртасында
Күк елан күргәндә дә.

И малайлар, сезгә әйтәм:
Урамда тиз үсәсең.
Үтерепләр йокы килсә,
Анысына түзәсең.

Үскәч тә йоклап була ул,
Үскәч үсәсе юк ла!
Элек йокламаган өчен
Әйдә туйганчы йокла!

«Аша, үсәрсең, – ди әни, –
Ашасаң, – ди, – көч иңә».
Тик... би-и-ик акрын үсәм мин,
Һаман да шул кечкенә!
Зуп-зур булыр идем,

кайчак
Үсүдән туктамасам.

Их, бик шәп үсәр идем мин,
Төннәрен йокламасам!..

## ӘТИЕМ

Очучы да түгел әти,
Көн саен күккә менә.
Берничә минутка түгел,
Бер көнгә – күпкә менә!

Әти көнләштереп йөри
Күктәге бар кошларны.
Җирдә дә ул кирәк кеше,
Әтисез бер эш бармый...

Карлы-буранлы көндә дә
Күк катыннан төшми ул.
Болытларга тиеп торган
Зур кранда эшли ул.

## КЫЗЫЛ АВЫЛ

Хикмәт ләса: бөтен өйләр
Кызыл төскә буялган күк.
Кояшның бар кызыллыгы
Безгә генә коелган күк.

Агачлар да, коймалар да,
Яр буйлары алсу-кызыл.
Әнкәй әнә алсу күлдән
Алып кайта алсу казын.

Яшел чирәм кызыл бездә,
Кызыл елга, кызыл инеш.
Юынып та карыйм кайчак,
Мин барыбер кызыл, имеш...

Үсеп кенә җитим әле,
Моның серен беләчәкмен.
Мин ул шәфәкъ кызыллыгын
Барып карап киләчәкмен!

## ӘДӘПЛЕЛЕК

Трамвайда барган чакта,
Бүген әдәп сакладым.
«Тәртипле» дигән данымны
Тулысынча акладым.

Өлкәннәргә дип куелган
Урынга утырмадым.
Кеше борчып, арлы-бирле
Чапмадым, котырмадым.

Тукталыш саен кешеләр
Гел чыгып-кереп торды.
Чыдадым, түздем.
Әнием
Мине күтәреп торды...

## МИНЕМ МӘШӘКАТЬ

Өйдә минем әни дә бар,
Өйдә минем әти дә бар.
Туңмасын дип алып кергән,
Яңа туган бәти дә бар.

Өйдә минем апам да бар,
Өйдә минем абый да бар.
Бертуктаусыз шелтәлиләр,
Аның шундый ягы да бар!

«Йомгак» дигән көчегебез
Учларымны ялап тора.
Койрыгыннан тартып йөртсәм,
Әти колагымны бора.

Һәр көн саен мең мәртәбә
Әби килеп сөеп китә.
Апа, түти, җиңги, җизни
Күчтәнәчләр өеп китә.

Әни йөри өзгәләнеп,
Мине һаман сабый күрә.
Назланасы килә дә соң...
Мин зур инде – абый күрә!

Шулкадәрле мәшәкатьне
Берүземә кем биргәндер?!
Тик барыбер сабыр итәм,
Аларга бит
мин – бердәнбер!

# МИНЕМ СЕРЕМ

Мин берәр эшкә керешсәм,
Күрше-күлән көлешә:
– Нәкъ әнисе инде менә, –
Бөтен эш тә килешә!
Бигрәк җиңел сөякләре,
Куллары алтын ласа.
Мамык кебек очып йөри,
Аккошлар кебек баса.
Әнисе кебек ягымлы,
Сөйкемле-назлы бала.

Һәр кеше, мине күрдисә,
Әнине танып ала.

Бәйләнмәгез!
Бүген сезгә
Бар серемне таратам:
Мин әнигә охшаганмын,
Чөнки аны өзелеп-өзелеп,
Өзелеп-өзелеп яратам!

# КАПИТАН

Олы кораблар йөздерәм,
Мин – диңгездә капитан.
Матур итеп сорасагыз,
Үзем белән апкитәм.

Тау чаклы дулкында кораб
Чак кына батмый кала.
Үзеннән зур балыклар да
Аны чак йотмый кала...

Җил-давылда капланса да,
Ни гаҗәп: батмый кораб.
Бер диңгез патшасы кебек,
Бер читтә торам карап.
Судан бер тамчы курыкмыйм.
Теләсәмме? Йөз керәм!

...Көн дә, качып, ваннабызда
Уенчыклар йөздерәм.

## ТУБЫМ

Быел минем туган көндә
Бер туп бүләк иттеләр.
Малайларның күзе кызды:
«Миңа бүләк ит!» – диләр.

Үземә дә ошады ул,
Беркемгә бирмим аны.
Кочагымда гына йөртәм,
Назлыйм, кадерлим аны.

Белеп торам: ул үзе дә
Мине генә үз күрә.
Пычратмыйм, юешләмим,
Югыйсә ул искерә.

Терт-терт итеп куып җитә,
Яр астына йөгерсәм.
Сикергәләп төшкән була,
Тауга чөеп җибәрсәм.

Шау килеп уйнап йөрибез,
Безне беркем дә тыймый.
Тәгәрәп яныма килә,
Тубым да мине таный...

## ҖАЕН ТАПТЫМ

Бер сәгатьтән кайтам, диеп,
Әни китте эше белән.
Кыен икән ялгыз калу,
Өйрәнгәч гел кеше белән.

Көпә-көндез күзләремә
Әллә ниләр күренгәли.
Бичуралар, шүрәлеләр
Арлы-бирле йөренгәли.

Җен-пәриләр белән тулган
Почмактагы киштә өсте.
Кинәт Яңа елдан калган
Эт битлеге искә төште.

Кызык иттем, җен күренсә,
Бертуктамый өреп тордым.
Курыкмадым, өй эчендә
Битлек киеп йөреп тордым!

## ТУГАН КӨНЕМ ҖИТӘ

Тиздән туган көнем җитә,
Мин моны белеп торам.
«Сиңа ничә яшь тула?» – дип
Сораша бөтен урам.

Туганнарны чакырырбыз,
Бик матур киенермен.
Кунак абый-апалардан
Туйганчы сөелермен.

Матур бүләкләр бирерләр,
Туган көн җитә инде.
Шуннан беләм: уенчыклар
Ватылып бетә инде!

## УҢГАН БУЛАСЫМ КИЛӘ

Әтием минем – игенче,
Трактор – бөтен эше.
Аның уңган булуына
Аптырый бөтен кеше.

Барлык эш киемнәренә
Тимер майлары тамган.
Әни һаман әйтеп тора:
«Әтиең шундый уңган!»

Мин дә бүген аның белән
Майга буялып йөрдем.
Трактор исе аңкытып,
Йөгереп кайтып кердем.

Ни әйтергә белми әни,
Өстемә караган да...
(Миңа ярамый микәнни,
Әтигә ярaганда?..)

– Нишләдең син, и улым? – ди, –
Пәри белән кундыңмы?!
– Әни, әни! Мин дә хәзер
Әти кебек уңдыммы?

## КЫЗЫК ИТӘРМЕН ӘЛЕ

Алсу дигән кыз бар бездә,
И кызык та кыз инде.
Малайларны санга сукмый,
Быел бигрәк узынды.

Дәрес буе карап торам,
Ә ул бер дә карамый.
Толымыннан тартыр идем,
Апа күрә – ярамый!

«Күчерт әле», – дигән булам,
Өй эшен эшләсәм дә.
Аның өчен генә алам
Тутырып «бишле»сен дә.

Дәшми, хет нишләсәм дә...

Тәнәфестә ялгыш кына
Кулыннан тотып китәм.
Урамга чыкса, йомарлап,
Аңа кар атып китәм...

Күрү белән, әллә нигә
Каушап төшәм алдында.
Зурлар дөрес әйтә икән:
Бар йөрәгем ялкында...

Туган көне генә җитсен,
Кызык итәрмен әле.
Бар урам каршында
чәчәк
Бүләк итәрмен әле!..

## ҮЗ БАШЫМА ӨЙРӘТТЕМ

Безнең Акбай ялкау булды:
Һич өрми, һич тешләми.
Җәй буе йоклап чыга ул,
Карак тотмый, тешләми...

Бүген, каршыма бастырып,
Бик әйбәтләп тиргәдем.
«Кичә, – дидем, – Нәсим керде,
Бер тамчы да өрмәдең.

Өченчекөн Бүре Илдар
Ике алманы өзгән.
Алманы өзеп калмаган,
Бөтен җиләкне изгән!»

Арыдым...
Ял итәр өчен
Вакыт табарга булдым.
Үрелеп кенә берничә
Җиләк кабарга булдым...

Шунда яныма, ырылдап,
Акбай килеп утырды.
Бер өрде дә терсәгемә
Үткен тешен батырды...

СИХЕР

Мәктәптә бер сихер бардыр:
Ант итәм – бер алдамыйм!
Тел бистәсенә әйләнәм,
Әллә нишлим анда мин.

Дәрескә кереп утырсам
Сөйләнәм дә сөйләнәм.
Лыгырдык бер кәмитчегә,
Клоунга әйләнәм.

Бу сихердән котылуның
Бер юлын да беләм мин:
Дәрес сорап бастырсалар,
Сихер бетә – мин ләм-мим!..

## ТУГАН ТӨН

Бу көнне бүләкләр биреп
Ялкытып бетерәләр.
«Туган көнең белән!» – диеп,
Ачуны китерәләр.

Белмиләрме?..
Көмеш айга,
Йолдызларга туган мин.

«Туган төнең» дип әйтегез,
Мин бит төнлә туганмын.

## ТҮБӘТӘЙ

Туган көнемдә дәү әти
Түбәтәй бүләк итте.
Дога укып кидерде дә
Мәгънәсен сөйләп китте:
«Түбәтәй – изге әйбер ул,
Аны кигән һәр кеше
Иманлы-инсафлы була,
Уңа аның һәр эше...»

Түбәтәй кигән көннән соң
Тәртип бозмадым бер дә.
Яшим шулай иң тәүфыйклы
Бер малай булып җирдә.

Күрше әбигә су кертәм,
Әнигә мал карашам.
Түбәтәйне аклар өчен,
Бар көчемә тырышам.
Мәктәптә дә яхшы укыйм, –
Көне буе мактыйлар.
Карышмагач, әллә күпме
Класс эшен тактылар.

Әлбәттә, бу түбәтәйне
Һәрчак акларга була...
Тик менә... Түбәтәй белән
Кыен чаклар да була.

Күрше партадагы Алсу
Минем якка карамый.
Чәченнән тартыр идем дә,
Түбәтәй бар – ярамый!

Түбәтәйне салып куеп,
Котырып йөрер идем.
Кайбер усал малайларның
Кирәген бирер идем!..
Ярамагач ярамый шул,

Күреп калыр дәү әти.
Гел әйбәтлек эшләттерә
Башымдагы түбәтәй.

...Төштә генә тәртип бозам:
Чабам, шаярам, ватам...
Мин бит кичен түбәтәйне
Шүрлеккә куеп ятам.

## БҮРЕ ҖИЛӘГЕ

Урманга баргач, бик матур
Бер җиләк тапкан идем.
Ашап туйгач, кесәләргә
Тутырып кайткан идем.

Ашамасам да үкенмим,
Кирәкми чиләге дә!
Чак үлмәдем...
Хәтәр икән
Бүренең җиләге дә!

## ТӘРТИП БОЗЫП ЙӨРДЕМ

Туйганчы бер!..
Рәхәтләнеп!..
Котырып йөрдем бүген.
Бүген генә ул...
Мин алай
Тәртипсез малай түгел.

Малайлар белән көрәшеп
Тирләдем, янып-пештем.
Багана башына менеп,
Ак әтәч урлап төштем.

Чүлмәк ватып йөрдем әле,
Аркан тартып уйнадым.
Иң ахырдан капчык белән
Бер малайны кыйнадым.

Акча эзләп, башым белән
Ачы катыкка кердем...

...Бүген мин, «тәртипсезләнеп»,
Сабан туенда йөрдем!

## СЕРЕБЕЗНЕ АЧТЫЛАР

Абый миңа бик охшаган,
Шуңа да гел бутыйлар.
Эндәшкәндә, исемнәрне
Гел ялгышып атыйлар.

Әле күптән түгел генә
Серебезне ачтылар.
Исемне әйтердән элек:
– Авызыңны ач! – диләр.

Ачасы килми авызны,
Аны ачсаң – хәтәр эш:
Биш тешем бар, абыемда
Хәзер инде унбер теш.

## ЯЛ КӨНЕ

Ял көне җитте исә,
Әти йоклый да йоклый.
Әнием кичкә кадәр
Телефон төбен саклый.

Бу ялда хәйләләштем,
Хәтта көлдем алардан.
Әллә ни кыен түгел
Көйләтү олылардан.

Бераз елап та алдым,
Бераз уйнап та алдым.
Бераз гына әтиемне –
«Әп-пә!» – кыйнап та алдым...

«Әйдәгез, – дим аларга, –
Бүген әйбәт булыгыз.
Сезнең өчен кызарып
Йөрмәс инде улыгыз!»

...Килеп чыктык шаулашып,
Шаккатып тора урам.
Әти белән әнине
Паркка алып барам!

ТАУ ШУДЫМ

Кызык иттем бүген мин:
Тау ясадым эскерттә,
Биек тау өйдем көрттә.
Бернәрсә дә булмады,
Барысы да тәртиптә!

Муеныма аз гына
Әчеттереп кар тулды.
Кителеп чыкты чаңгым,
Тун итәге ертылды...
Борыным канап алды,
Анысына да түздем.
Кечтеки генә әйбер –
Бүрекнең бавын өздем...
Бар җиремә кар тулды,
Коенып чыктым көрттә.

Әйттем бит инде, әйттем:
«Барысы да тәртиптә!..»

## КЫШКЫ БАКЧА

Бүген бакчага кердем дә
Аптырап карап торам.
Кызганыч, беркем дә күрми,
Көрт артында бар урам.

Бәс кунган алмагачларда
Алмалар эленеп тора.
Шулкадәр дә серле алар,
Тылсымлы, беленеп тора!

Алтынсу, алсу, кызылы...
Тагын әллә ниндиләр...
Гүя берсен берсе бүлеп:
«Иң матуры – мин!» – диләр.

Аптырарсың да, алмага
Бар бакча тулган ласа!
Өзим дисәм...
Алмаларым
Кызылтүш булган ласа!

## МИН ШУНДЫЙ!

Кыштан мин һич зыян күрмим,
Кыш көне бер өшемим.
Чөнки минем тик торган юк,
Өлгер, җитез кеше мин!

Әнигә су алып кайтам,
Әтигә мал карашам.
Бераз тау да шуып алам,
Эшләр эшләп арысам.

Суык ялкауны өшетә
Йә, үчекләп, кар ата.
Уңганнарны үз итә кыш,
Өлгерләрне ярата!

## ЭТ БУЛДЫМ

Быел кыш
            әтием миңа
Өр-яңа бүрек алды.
Беренче көнне үк аны
Мәчебез күреп калды.

Күреп кенә калды да бу
И мырларга кереште.
Кабарынып йөри теге,
Эшләп булмый бер эшне.

Юри генә өргән идем,
Шундук торып чапты ул.
Эт тиресеннән тегелгән
Бүрек булып чыкты ул.

Менә алар: Самат, Марат,
Барый, Хәлим, Мирвәли.
Алсу дигән күрше кызы
Яннарында йөргәли.

Берәр кеше карап торса
Гаҗәпләнер, шаккатыр:
Алты бала арасында
Шушы Алсу – иң батыр!

Эт күрсәләр, ах-ух килеп,
Малайлар кача элек.
Усал күркә янында да
Бер Алсу тора көлеп.

Малайлар кермәгән җиргә
Курыкмый йөзеп керә.
Иң биек агачка менеп,
Җимешен өзеп бирә.

Ул йөргән капка башына
Малайлар көчкә менә.
Таганда атынган чакта,
Алсу иң өскә менә...

Шуңа күрә тирәсендә
Малай-шалай йөргәли.
Кемнәр дисәң: Самат, Марат,
Барый, Хәлим, Мирвәли.

ӘЛЕГӘ ТҮЗӘМ

Безнең урам малайлары –
Нәсим, Рәсим, Барыйлар –
Үз абыйлары хакында
Мактанып та карыйлар!

Нәсим әйтә: «Минем абый
Көрәштә иң батыры!»
Рәсим әйтә: «Минем абый
Мыеклы – иң матуры!»

Барый чәчрәп алга чыга:
«Минем абый, белсәгез...
Кулларында йөри ала,
Ышанырсыз күрсәгез...»

Миндә – апа... Әгәр дәшсәм,
Бөтен малай көләчәк.
Түзәм... Чөнки озакламый
Барысы миңа киләчәк.

Абыйларыннан хат ташып
Интектерерләр әле.
Апа хакында сөйләүне
Көтеп йөрерләр әле!..

«МИН»ЛЕ ӘХМӘТ

Күршедә бер малай яши,
Исеме – Миңлеәхмәт.
Әбисе кушкан,
Качсын дип
Аңардан җенле зәхмәт.

Тик нишлисең, Хак Тәгалә
Язса язмыш тактаңа...
Миңлеәхмәт көннәр буе
Мактана да мактана.

– Мин авылда иң батыры,
Иң матуры урамда.
Курыкмыйча йөри алам
Күз ачкысыз буранда.
Биек таудан шуып төшәм,
Мин барыбер егылмыйм.
Качышлы уйнаган чакта
Эзләмә дә – табылмыйм!
Мин ялгызым өйдә калам,
Куркытмый җен-пәри дә!
Мин кызармыйм, очраса
Күрше кызы Фәридә.
Мин шәп итеп рәсем ясыйм,
Исләрең китәр күрсәң.
Беркем куып җитә алмый,
Сабантуйда йөгерсәм.

...Һәрбер эштә иң беренче,
Барысыннан алда ул.
Миңле булмады бу Әхмәт,
«Мин»ле Әхмәт булды ул!..

## САБИРГА НӘРСӘ БУЛГАН?

Әллә нәрсә булган бүген
Төпчек энем Сабирга,
Мәктәптән кайтып керүгә
Чыкты келәм кагарга.

Су алып кайтты йөгереп,
Утын кертте ягарга.
Күренеп тора: бик каты
Тырыша бу ярарга...

«Әнием!» – дип өзелеп тора,
«Әти!» – дип сырпалана.
Эштән бушаган арада,
Әллә ниләр кылана...

Җырлап җибәргән була ул,
Уйный башлый гармунда...
Аптырыйлар өйдәгеләр:
– Ниндидер сер бар монда!

Ачыкланды.
Олы абый
Сәбәбен белеп кергән:
– Бүген, – ди, – Сабир энебез
«Икеле» эләктергән.

## КЫШ БАБАЙГА – «ИКЕЛЕ»!

Дәресен эшләп куя да
Тагын тәрәзгә карый.
Тәрәзгә караган саен,
Гел шуны уйлый Барый:

«Кыш, кыш, диләр, нинди кыш бу?
Шәһәр өсте кап-кара!
Ә бит кышын ап-ак карга
Бөтен дөнья яктыра.

Чын кышта чын көртләр була,
Кышкы буран и тиле!
Дәресен эшли алмаган
Кыш бабайга – «икеле»!»

## МӘҮЛЕТ – МӘҮЛӘВИ

### Безнең урам малайлары

Кызык уен таптылар.
Очраган һәр малайга
Бер кушамат тактылар.

Шәүкәт – Шәвәли булды,
Самат – Сәмәви булды,
Хәммәт – Хәмәви булды,
Сәләт – Сәләви булды...

Һәр малайда «әви» бар,
Нигә елый Мәүләви?
Аның үзендә – «әви»,
Шуңа борын әвәли...

Инде хәзер нишләргә,
Мәүләвигә исем юк?
«Табыгыз ничек тә, – ди, –
Анда минем эшем юк!»

Көн буе баш ваттылар,
Рәхәт түгел уйлавы.
Ахыр чиктә таптылар:
Мәүлет булды Мәүләви!

## БАБАЙ БЕЛӘН МАЛАЙ

Җитәкләшеп, урам аша

Ике кеше чыгып бара.
Тыз-быз чаба машиналар,
Курыкмыйча чыгып кара!

Берсе аның бабай кеше,
Берсе аның гел нарасый!
Күпме гомер чыксалар да,
Һич кимеми юл арасы.

Бабай кеше як-ягына
Минут саен карап ала.
Малай кеше бабасының
Хәл-әхвәлен сорап ала.

Ике бөртек җан иясе
Бер-берсенә елышадыр.
Аңламассың: бу вакытта
Кайсы кемгә булышадыр?

## КЫШ БАБАЙ КИЛӘ

Һәр ел чыршы бәйрәменә

Кыш бабай килә безгә.
Зурларга җырлар өләшә,
Бүләкләр – энебезгә.

«Кар бабай», «Суык бабай» дип
Йөрибез Кыш бабайны.
Узган ел да өшетте ул
Урамда биш малайны.

Шулай да бераз шигем бар
Кыш бабайга карата.
Безнең белән, янып-пешеп,
Ул биергә ярата.

Кайсы гына малай аны
Яңа елда күрмәгән:
Бүрегеннән парлар чыга,
Бөтен бите тирләгән.

Кызык инде:
          тышка чыксаң,
Сап-салкын кар ата ул.
Бүлмәдә җылына,
                    чөнки
Балалар ярата ул!

## ШУГАЛАК

Нинди матур шугалак –

Илдар йөри шугалап.
Таеп китеп егылдисә,
Йөри терсәк угалап...
Шуган чакта, өрә-өрә,
Этләр чаба кугалап...

Нинди матур шугалак!
Илдар йөри шугалап.
Көн дә су ташый, буранда
Калмасын, ди, югалып...
Су сипкәндә, ялгыш кына
Барып төшә суга – «лып»!

Илдарларның өй каршында
Шундый кызык шугалак!
Мин дә алам шугалап...

## БАРМАК БӘЛАСЕ

Суык диеп тормаган,

Кимме әллә кешедән. –
Наил уйнарга чыккан,
Тик... куллары өшегән!

Юри сораган булам:
«Яшең, – димен, – ничәдә?»
«Әйтә алмыйм, – ди Наил, –
Бармакларым кесәдә».

## КОВБОЙ

«Бүген мин ковбой булам!» – дип,
Барый эре мактанды.

Мактанып кына калмады,
Бер бозауга атланды.

Бозауга бу ошамады,
«Ковбой» барып капланды.

«Бозау кино карамый шул», –
Диеп, Барый акланды.

## БЕРНИ БУЛМАДЫ

Бүген, тау шуганда, Римнең